# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

№ 5

28.10.2023 ел

**"Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Сидулово-Ерыклы торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Уставының 24 статьясына ярашлы, "Аксубай муниципаль районының Урмандеево авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы КАРАРы:

1.Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Сидулово-Ерыклы авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1) Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Сидулово-Ерыклы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәттә булучылардан, мобилизацияләнгән затлар һәм аларнын гайлә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә , алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1)торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (ташлар сатып алу, ташу,юлларны кышкы тоту килешү буенча эш өчен түләү )

2) күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аңа якын территорияне төзекләндерү (һәйкәлне саклау төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү

3) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

-су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирү (халыкка су бирү өчен кабель сатып алу)тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыеннарны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны Урмандеево авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга. http://aksubaevo.tatar.ru, ТР Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандеево авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев